Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы
Иске Гришкино авыл җирлегенең
Карманково авылында гражданнар җыены

Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы
Иске Гришкино авыл җирлегенең
Карманково авылында гражданнар җыены
нәтиҗәләре турында

от 18.11.2024 г. №3

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Иске Гришкино авыл җирлеге башлыгының 2024 елның 8 ноябрендәге 13 номерлы «Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Иске Гришкино авыл җирлегенең Карманково авылында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү буенча гражданнар җыенын билгеләү турында” карары нигезендә 2024 елның 18 ноябрендә Менделеевск муниципаль районы Иске Гришкино авыл җирлегенең Карманково авылы гражданнар җыенының йомгаклау беркетмәсе төзелде: сайлау хокукына ия җыенда катнашучылар исемлегенә 49 граждан кертелгән, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар саны 31 граждан. Ачык тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде: "ӘЙЕ" - 31 граждан тавыш бирде; "ЮК" - 0

Бәян ителгәннәр нигезендә, гражданнар җыены КАРАР КЫЛДЫ:

1. Менделеевск муниципаль районының Иске Гришкино авыл җирлегенең Карманково авылында гражданнар җыенын узган дип санарга, җыен нәтиҗәләрен дөрес дип танырга.

2. 2025 елда Менделеевск муниципаль районы Иске Гришкино авыл җирлегенең Карманково авылында яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән I-II төркем инвалидлардан, Бөек Ватан сугышы тыл ветераннарыннан, 18 яшькә кадәр тәрбиядә балалары булган аз керемле күпбалалы гаиләләрдән, көндезге бүлектә укучы студентлардан, Россия Армиясе сафларына сроклы хезмәткә чакырылган гражданнардан, югары һәм урта уку йортларының көндезге бүлегендә укучы студентлардан тыш, 1000 сум күләмендә үзара салым акчаларын кертүгә һәм алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен түбәндәге ихтыяҗларга юнәлтергә сез ризамы" дигән сорау каралды һәм расланды.

«1) тышкы яктырту урам челтәрләрен, трансформатор һәм башка подстанцияләрне һәм алар астындагы мәйданчыкларны, бүлү пунктларын һәм электр элемтәләрен тәэмин итү һәм электр энергиясен тапшыруны гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән башка җайланмаларны ремонтлау (Карманково т. п. урам яктырткычларын урнаштыру);

3) торак пункт территориясен төзекләндерү (үлән чабу, кышкы чорда юлларны кардан чистарту).»

3. Әлеге карарны Иске Гришкино авыл җирлегенең мәгълүмат стендларына урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә, Менделеевск муниципаль районының рәсми сайтында “Иске Гришкино авыл җирлеге” бүлегендә (http://mendeleevsk.tatarstan.ru), Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында www.pravo.tatarstan.ru бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Иске Гришкино авыл җирлеге башлыгына Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Халык җыенында рәислек итүче,
Менделеевск муниципаль районы
Иске Гришкино авыл җирлеге башлыгы_______________ К.И.Алексеев
(имза) (имзаның аңлатмасы)